# РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘПЛӘРЕНЕҢ 5 НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ӨЧЕНТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘН АГЫМДАГЫ АТТЕСТАЦИЯНЕ УЗДЫРУ ӨЧЕН ҮРНӘК МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ (СПЕЦИФИКАЦИЯ) (5НЧЕ СЫЙНЫФ)

**1.** Контрольтикшерү материаллары рус телендә белем бирү мәктәпләренең 5 нче сыйныф укучылары өчен туган (татар) телдән агымдагы аттестацияне уздыру өчен әзерләнде.

**2. Үрнәк материалларының төзелешен һәм эчтәлеген билгеләү алымнары**

Агымдагы аттестация биремнәре түбәндәге бүлекләр кысасында төзелде: укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән биремнәр; укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү биремнәре; укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә йөз тоткан биремнәр һәм укучыларның язу күнекмәләрен һәм телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерү биремнәре. Әлеге биремнәр тел белеменең фонетика һәм графика, орфография һәм орфоэпия, лексика һәм грамматика, сөйләм үстерү кебек тармакларны үз эченә ала.

**3. Агымдагы аттестациятестының төзелеше һәм эчтәлегенә аңлатма**

Үрнәк вариант катлаулылыгы ягыннан төрле 12 биремнән тора.

Түбәндәге таблицада биремнәрнең төп бүлекләргә бүленеше бирелә.

| **Эчтәлек бүлекләре** | **Биремнәрнең саны** |
|---|---|
| 1. Укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерү биремнәре | 3 |
| 2. Укучыларның укукүнекмәләрен тикшерү | 2 |
| 3. Укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерү | 5 |
| 4. Укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү биремнәре | 1 |
| 5. Укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерү биремнәре | 1 |
| 6. Барлыгы | 12 |

Тестта өч төрле бирем кулланыла: сайлап алуны таләп иткән биремнәр (А), тәңгәлләштерү (В), киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәр (С).

| Биремнәрнең типлары | Тесттагы гомуми саны | Бирем номеры |
|---|---|---|
| Сайлап алу тестлары | 7 | 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 |
| Тәңгәлләштерү тестлары | 1 | 8 |

| | | |
|---|---|---|
| Кыскача җавап таләп иткән бирем | 2 | 9,  10 |
| Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәр | 2 | 11, 12 |

4. **Биремнәренең катлаулылык дәрәҗәсе ягыннан бүленеше**

| **Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе** | **Биремнәр саны** | **Иң югары башлангыч балл** |
|---|---|---|
| Нигез (база) | 10 | 12 |
| Югары | 2 | 6 |
| Барлыгы: | 12 | 18 |

**5. Аерым биремнәрне һәм барлык эшне бәяләү системасы**

**1 нче бүлектәге** 1-3 нче биремнәр аудиоязманы тыңлаганнан соң башкарыла. Тибы ягыннан бу биремнәр сайлап алу биремнәренә карый. Бу бүлектәге һәр дөрес җавап өчен укучыга 1 балл куела. Ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса, 0 балл куела.

Бу бүлектә дөрес җаваплар өчен укучы иң югары **3** балл җыя ала.

**2 нче бүлектәге** биремнәркыска җавап язуны таләп итә, биремнәрдәге җөмләләрне укучы укый, аннан соң җавабын яза. Ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса, 0 балл куела.

Бу бүлектә дөрес җаваплар өчен укучы иң югары **3 балл** җыя ала.

**3 нче бүлектәге** биремнәр өч типка карый. 6-7 нче биремнәр сайлап алу биреме булып тора, бу биремнәргә 1 балл куела. Ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса, 0 балл куела.

8 нче бирем – тәңгәлләштерү тибына карый. Бу биремгә 2 балл куела. Ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса, 0 балл куела.

9- 10 нчы биремнәр кыска җавап язуны таләп итә, һәр җавап 1 балл белән бәяләнә. Бу биремнәргә ялгыш җавап бирелсә яки җавап булмаса, 0 балл куела.

Бу бүлектә дөрес җаваплар өчен укучы иң югары **6 балл** җыя ала.

**4 нче бүлектәге** биремдә укучылар җөмләгә 6 сүз өстәп язарга тиеш.

Бу биремне бәяләү критерийлары:

| **Бәяләү критерийлары** | **Балл** |
|---|---|
| Җөмлә дөрес төзелгән һәм дөрес язылган, 6 сүз өстәлгән җөмлә ахырында нокта куелган | 3 |

| | |
|---|---|
| Сүзләр төзелешендә 1 хата бар **яки** җөмләгә 5 сүз өстәлгән. | 2 |
| Сүзләр төзелешендә 1 хата бар **һәм** җөмләгә 4 сүз өстәлгән. | 1 |
| Икедән артык хата бар, сүзләр саны 4 тән ким | 0 |

**5 нче бүлектәге** биремдә укучының телдән сөйләм күнекмәләре тикшерелә. Укучы бирелгән темага 5 бәйләнешле җөмлә төзеп әйтергә тиеш. Туган телнең лексик, грамматик, орфоэпик нормалары, басым, интонация үзенчәлекләре исәпкә алына.

| **Бәяләү критерийлары** | **Балл** |
|---|---|
| Җөмләләр логик төзек, бәйләнешле,тел нормалары сакланган, сүз басымы дөрес куела. | 3 |
| Җөмләләр логик төзек, тел нормаларын куллануда хата бар **яки** сүз басымы дөрес куелмый. | 2 |
| Җөмләләрдә сүзләр бәйләнеше бозылган **яки** логик эзлеклелек сакланмый;<br>тел нормаларын куллануда 1 хата бар **яки** сүз басымы дөрес куелмый;<br>логик эзлеклелек сакланмый, **әмма** укучының сөйләме орфоэпик нормаларга буйсынган. | 1 |
| Икедән артык хата бар | 0 |

Биремнәрне үтәү барышында җыелган **иң югары балл** – 18. Индивидуаль бәяләү укучының җыйган балларыннан чыгып эшләнә. Җыелган баллардан чыгып, нәтиҗәләр түбәндәгечә бәяләнә:

0-4 – түбән дәрәҗә, **2 ле билгесе**;
5-8 – канәгатьләнерлек, **3 ле билгесе**;
9-13 – урта дәрәҗә, **4 ле билгесе;**
14-18 – югары дәрәҗә, **5 ле билгесе.**

**6. Тестны үтәү шартлары**

Тест уку елы башында үткәрелә. Тестны үтәү өчен, 45 минут вакыт бирелә. Биремнәрне үтәү вакыты 9 пункттагы гомумиләштерелгән планда күрсәтелгән.

12 нче биремнең җавабын тестны эшләп бетергәч тыңлау кирәк.

**7. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар**

Тестны үтәү барышында сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

**8. Үрнәк материалларның гомумиләштерелгән планы**

*Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе: Н – нигез (база), Ю (югары)*

| № | Тикшерелә торган эчтәлек элементлары | Тикшерелә торган эчтәлек кодлары | Тикшерелә торган күнекмәләр | Биремнең катлаулылыгы | Бирем өчен иң югары балл | Бирем-не үтәү вакыты (мин) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерү биремнәре | | | | | | |
| 1. | Текст белән эш | 9.3 | Аудио- һәм видеотекстларның төп эчтәлеген аңлый белү | Н | 1 | 3 |
| 2. | Телдән һәм язма сөйләм | 9.1 | Төрле функциональ-мәгънәви сөйләм тибындагы укыган һәм тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлый белү | Н | 1 | 3 |
| 3. | Текст белән эш | 9.3 | Телдән һәм язма сөйләмдәге мәгълүматны дөрес, төгәл аңлый белү | Н | 1 | 3 |
| 2. Уку күнекмәләрен тикшерү | | | | | | |
| 4 | Текст белән эш | 9.3 | Төрле функциональ-мәгънәви сөйләм тибындагы укыган һәм тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлый белү | Н | 1 | 2 |
| 5 | Текст белән эш | 9.3 | Укыган тексттагы тел чараларын таба, аларның үзенчәлекләрен аңлата белү | Н | 2 | 3 |
| 3. Лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерү биремнәре | | | | | | |
| 6 | Сузык һәм тартык хәрефләр һәм авазлар | 1.3 | Авазларны аера һәм аларның мәгънә аеруга хезмәт итүләрен белү | Н | 1 | 2 |
| 7 | Тамырдаш сүзләр | 5.5 | Сүзгә морфемик һәм сүз ясалышы ягыннан анализ ясый белү | Н | 1 | 2 |
| 8 | Сүз мәгънәсен аңлату ысуллары | 4.2 | Татар һәм рус телләренең лексик составын чагыштыра белү | Н | 1 | 2 |
| 9 | Алынмалар | 4.7 | Лексик белгеләренә нигезләнеп, сүзнең кулланылыш, килеп чыгышы, активлыгы ягыннан билгеле бер төркемгә каравын билгели белү | Н | 2 | 2 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Исем сүз төркеме | 6.3 | Сүз төркемнәренең грамматик категорияләрен аера һәм аларны төрләндерә белү | | 1 | 3 |
| 4. Язу күнекмәләрен тикшерү биреме | | | | | | |
| 11 | Телдән һәм язма сөйләм | 9.1 | Татар телендәге сүз тәртибен аңлап, җөмләләр төзи белү | Ю | 3 | 5 |
| 5. Телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерү | | | | | | |
| 12 | Диалогик һәм монологик сөйләм | 9.2 | Өйрәнгән орфографик һәм орфоэпик кагыйдәләрне дөрес кулланып, язмача һәм телдән кечкенә текст төзи белү | Ю | 3 | 15 |

## Кодификатор

Татар теленнән әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба – кодификатор) – арадаш аттестациянең эчтәлеген билгеләүче документларның берсе.

Кодификатор белем эчтәлегенең һәм аңа куелган таләпләрнең системалы бирелешен хасил итә. Тикшерү материаллары кысасында бирелгән материаллар гомуми белем бирү Федераль дәүләт белем бирү стандартына (ФГОС ООО), үрнәк гомуми белем бирү программасына (ПОП), дәреслек һәм уку-укыту әсбапларына нигезләнеп, аларда куелган таләпләргә туры китерелеп төзелде. Кодификатор эчтәлегендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслекләргә, белем бирү программаларына кертелмәгән әзерлек дәрәҗәсе таләпләре чагылыш тапмый.

Материаллар бирелеше үрнәк белем бирү программасында күрсәтелгән дүрт блок кысасында һәм шулар эчендә бирелгән тел, стилистика һәм телдән һәм язма сөйләм материалын үзләштерү буенча белемнәрне тикшерүне күзаллый.

Кодификаторда эчтәлеге төп тематик блоклар эчендәге киңрәк булган тармаклар, калын курсив хәрефләр белән язылып, кечерәк блокларга бүленде. Кодификаторның әлеге позицияләренең һәрберсе укыту эчтәлегенең берләштерелгән дидактик берәмлекләрен тәшкил итә. Аларга берничә тематик берәмлек керә ала. Тикшерү биреме төзеләчәк эчтәлек элементының коды икенче баганада күрсәтелә.

### 1 нче бүлек. Туган (татар) теленнән арадаш аттестациядә тикшереләчәк эчтәлек элементларының исемлеге

| Бүлек коды | Тикшерелә торган элемент коды | Тикшерелә торган материалның эчтәлеге |
|---|---|---|
| **1** | | ***Фонетика*** |
| | 1.1 | Сөйләм органнары. Авазларның ясалу урыны |
| | 1.2 | Сингармонизм законы |
| | 1.3 | Сузык һәм тартык хәрефләр һәм авазлар |
| | 1.4 | Татар һәм рус телләрендәге сузык авазлар |
| | 1.5 | Татар һәм рус телләрендәге тартык авазлар |
| | 1.6 | Сузыклар өлкәсендәге аваз үзгәрешләре |
| | 1.7 | Тартыклар өлкәсендәге аваз үзгәрешләре |
| | 1.8 | Иҗек. Иҗек типлары |
| | 1.9 | Басым. Интонация |
| | 1.10 | Сүзгә фонетик анализ |
| **2** | | ***Орфография*** |
| | 2.1 | Орфограмма |
| | 2.2 | о-ы, ө-е хәрефләренең дөрес язылышы |
| | 2.3 | ң, ж, һ хәрефләренең дөрес язылышы |
| | 2.4 | ъ-ь билгеләрнең дөрес язылышы |
| | 2.5 | е, ё, ю, я хәрефләренең дөрес язылышы |
| | 2.6 | Ике авазга билге булган хәрефләрнең дөрес язылышы |
| | 2.7 | Татар орфографиясенең катлаулы очраклары |
| | 2.8 | Алынма сүзләргә кушымчалар ялгану үзенчәлекләре |
| | 2.9 | Татар теленең орфографик сүзлеге |
| | 2.10 | Графика һәм орфография |
| | 2.11 | Орфографик принциплар |
| **3** | | ***Орфоэпия*** |
| | 3.1 | Татар теле орфоэпиясе турында төшенчә |
| | 3.2 | Орфоэпик нормаларның бозылуы |
| | 3.3 | Татар телендә сүз басымының үзенчәлеге |
| **4** | | ***Лексика һәм фразеология*** |
| | 4.1 | Сүзнең лексик мәгънәсе |
| | 4.2 | Сүз мәгънәсен аңлату ысуллары |
| | 4.3 | Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр |
| | 4.4 | Туры мәгънәле һәм күчерелмә мәгънәле сүзләр |

| | | |
|---|---|---|
| | 4.5 | Омонимнар. Антонимнар. Синонимнар |
| | 4.6 | Һөнәри лексика |
| | 4.7 | Алынмалар |
| | 4.8 | Актив һәм пассив лексика |
| | 4.9 | Искергән сүзләр |
| | 4.10 | Неологизмнар |
| | 4.11 | Фразеологик әйтелмәләр |
| | 4.12 | Сүзгә лексик анализ |
| **5** | | ***Морфемика һәм сүз ясалышы*** |
| | 5.1 | Сүзнең мәгънәле кисәкләре (морфемалар) |
| | 5.2 | Сүзнең тамыры |
| | 5.3 | Сүзнең нигезе |
| | 5.4 | Аффикслар |
| | 5.5 | Тамырдаш сүзләр |
| | 5.6 | Сүз ясалышының төп ысуллары |
| | 5.7 | Сүзгә морфемик һәм ясалышы ягыннан анализ |
| **6** | | ***Грамматика. Морфология*** |
| | 6.1 | Сүз төркемнәре |
| | 6.2 | Мөстәкыйль сүз төркемнәре |
| | 6.3 | Исем сүз төркеме |
| | 6.4 | Исемнәрнең килеш, сан, тартым белән төрләнеше |
| | 6.5 | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше |
| | 6.6 | Сыйфат сүз төркеме |
| | 6.7 | Сыйфатларның исемләшүе |
| | 6.8 | Алмашлык сүз төркеме |
| | 6.9 | Сан сүз төркеме |
| | 6.10 | Фигыль сүз төркеме |
| | 6.11 | Затланышлы фигыльләр |
| | 6.12 | Фигыльдә заман категориясе |
| | 6.13 | Ярдәмче фигыльләр |
| | 6.14 | Хикәя фигыль |
| | 6.15 | Боерык фигыль |
| | 6.16 | Теләк фигыль |
| | 6.17 | Шарт фигыль |
| | 6.18 | Затланышсыз фигыль формалары |
| | 6.19 | Инфинитив |
| | 6.20 | Исем фигыль |
| | 6.21 | Сыйфат фигыль |

| | | |
|---|---|---|
| | 6.22 | Хәл фигыль |
| | 6.23 | Рәвеш сүз төркеме |
| | 6.24 | Аваз ияртемнәре |
| | 6.25 | Модаль  сүз төркемнәре |
| | 6.26 | Ымлыклар |
| | 6.27 | Модаль сүзләр. Хәбәрлек сүзләр |
| | 6.28 | Кисәкчә |
| | 6.29 | Бәйлек һәм бәйлек сүзләр |
| | 6.30 | Теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр |
| | 6.31 | Сүзгә морфологик анализ |
| **7** | | ***Грамматика. Синтаксис*** |
| | 7.1 | Сүзтезмә һәм җөмлә |
| | 7.2 | Җөмләнең баш кисәкләре |
| | 7.3 | Җөмләнең иярчен кисәкләре |
| | 7.4 | Тиңдәш кисәкләр |
| | 7.5 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр |
| | 7.6 | Бер составлы һәм ике составлы җөмләләр |
| | 7.7 | Җөмләдә кереш сүзләр һәм мөрәҗәгать сүзләре |
| | 7.8 | Гади җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 7.9 | Гади җөмләгә синтаксик анализ |
| | 7.10 | Кушма җөмлә турында төшенчә |
| | 7.11 | Тезмә кушма җөмләләр |
| | 7.12 | Теркәгечле тезмә кушма җөмлә |
| | 7.13 | Теркәгечсез тезмә кушма җөмлә |
| | 7.14 | Тезмә кушма җөмләдә тыныш билгеләре |
| | 7.15 | Иярченле кушма җөмлә, төрләре |
| | 7.16 | Синтетик иярчен кушма җөмлә. Синтетик бәйләүче чаралар |
| | 7.17 | Аналитик иярчен кушма җөмлә. Аналитик бәйләүче чаралар |
| | 7.18 | Иярченле кушма җөмләләрнең төрләре |
| | 7.19 | Татар һәм рус телләрендә җөмлә үзенчәлекләре |
| | 7.20 | Кушма җөмләгә синтаксик анализ |
| | 7.21 | Чит сөйләмнең бирелеше |
| | 7.22 | Туры һәм кыек сөйләм |
| | 7.23 | Диалог |
| **8** | | ***Стилистика*** |

| | | |
|---|---|---|
| | 8.1 | Фразеологизмнарның сөйләмдә куллану үзенчәлекләре |
| | 8.2 | Синтаксик синонимнар |
| | 8.3 | Сүзтезмәләрнең синонимлыгы |
| | | Сөйләм стильләре |
| | 8.4 | Фәнни стиль |
| | 8.5 | Рәсми эш кәгазьләре стиле |
| | 8.6 | Сөйләм стиле |
| | 8.7 | Әдәби стиль |
| | 8.8 | Публицистик стиль |
| **9** | | ***Сөйләм. Сөйләм культурасы*** |
| | 9.1 | Телдән һәм язма сөйләм |
| | 9.2 | Диалогик һәм монологик сөйләм |
| | 9.3 | Текст белән эш |
| | 9.4 | Татар теленең башка телләр арасында тоткан урыны |

## 2 нче бүлек. Туган (татар) телдән арадаш аттестациядә тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр исемлеге

| Таләп коды | Тикшерелә торган күнекмәләрнең исемлеге |
|---|---|
| 1 | Авазларны аера һәм аларның мәгънә аеруга хезмәт итүләрен белү |
| 2 | Татар һәм рус телләрендәге авазларның аермалы якларын белү |
| 3 | Басым, интонацияне тоеп, дөрес куллана белү |
| 4 | Орфографик нормаларны язма сөйләмдә дөрес куллана белү |
| 5 | Сөйләмне татар әдәби теленең әйтелеш (орфоэпик) нормалары ягыннан бәяли белү |
| 6 | Фонетика, лексика, сүз ясалышы, морфология, синтаксис буенча алган белемнәрен телнең орфографик нормаларына яраклаштырып куллана белү |
| 7 | Сүзгә фонетик анализ ясый белү |
| 8 | Лексик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең кулланылыш, килеп чыгышы, активлыгы ягыннан билгеле бер төркемгә каравын билгели белү |
| 9 | Сөйләмдә антоним, омоним, синонимнарны, фразеологик әйтелмәләрне аера һәм куллана белү |
| 10 | Сүзгә лексик анализ ясый белү |
| 11 | Сүзнең состав өлешләрен аера белү |
| 12 | Татар телендәге төп сүз ясалышы ысулларын аера белү |
| 13 | Сүзгә морфемик һәм сүз ясалышы ягыннан анализ ясый белү |

| | |
|---|---|
| 14 | Лексик, төзелеш һәм ясалыш, морфологик һәм синтаксик билгеләренә нигезләнеп, сүзнең билгеле бер сүз төркеменә каравын билгели белү |
| 15 | Татар һәм рус телләренең лексик составын чагыштыра белү |
| 16 | Сүз төркемнәренең грамматик категорияләрен аера һәм аларны төрләндерә белү |
| 17 | Сүз төркемнәрен сөйләмдә дөрес куллана белү |
| 18 | Сүзгә морфологик анализ ясый белү |
| 19 | Сүзтезмә һәм җөмләнең төп үзлекләрен белү |
| 20 | Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аера белү |
| 21 | Гади җөмлә төрләрен аера һәм сөйләмдә дөрес куллана белү |
| 22 | Кушма җөмләгә хас үзенчәлекләрне белү |
| 23 | Кушма җөмләнең төрләрен аера һәм сөйләмдә дөрес куллана белү |
| 24 | Рус һәм татар телләрендәге җөмләләрнең аермалыкларын аңлау |
| 25 | Туры һәм кыек сөйләмне аера һәм дөрес куллана белү |
| 26 | Чит сөйләмне бирүдә цитаталар куллана алу |
| 27 | Тыныш билгеләренең куелышын аңлата белү |
| 28 | Сөйләм эшчәнлеге барышында, татар теленең синтаксик нормаларыннан тайпылмау |
| 29 | Җөмләгә синтаксик анализ ясый белү |
| 30 | Аудио- һәм видеотекстларның төп эчтәлеген аңлый белү |
| | Төрле функциональ-мәгънәви сөйләм тибындагы укыган һәм тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлый белү |
| | Укыган тексттагы тел чараларын таба, аларның үзенчәлекләрен аңлата белү |
| 31 | Язмача белдерелгән фикерне тел материалының кулланылышы ягыннан, таләп ителгән коммуникатив бурычларга ирешә алуга ярдәм итә алуы ягыннан бәяли белү |
| 32 | Телдән һәм язма сөйләмдәге мәгълүматны дөрес, төгәл аңлый белү |
| 33 | Сөйләм стильләрен билгели белү |
| 34 | Текстның эчтәлеге турында кыскача төгәл мәгълүмат бирә белү |
| 35 | Башлангыч текстның эчтәлеген аңлый һәм аңлатып бирә белү |
| 36 | Башлангыч текстка нигезләп, үз фикереңне эзлекле белдерә белү |
| 37 | Сөйләмдә телнең лексик байлыгыннан, төрле грамматик конструкцияләрдән урынлы куллана белү |
| 38 | Язма һәм телдән сөйләмне әдәби телнең орфографик, грамматик һәм пунктуацион нормалары нигезендә төзи белү |

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 12 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 10 нчы биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 11 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

## 1 нче бүлек

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Вакыйга кайда бара?

1) урам чатында

2) фатирда

3) кибеттә

**2.** Кемнәр урам чыга?

1) малай белән әтисе

2) малай белән әнисе

3) малай белән әби

**3.** Бу – дөресме?*Урам аша  бер малай белән бабай чыгып килә*.

1) дөрес 2) дөрес түгел

## 2 нче бүлек

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** Марат, (таш/үлән/яфрак) атып, кошларны куркыта.

**5**. Менә бер кош Маратның баш (очыннан/очына/очының) ук очып үтте.

## 3 нче бүлек

Укыгыз һәм  6-10 нчы биремнәрне эшләгез.

**6.** Хәрефләргә караганда авазлар саны күбрәк булган сүзне билгеләгез.

1) төньяк
2) бияләй
3) кәгазь

**7.** Тамырдаш сүзләрне билгеләгез.

1) болыт, болын

2) яшел, яшеллек
3) кул, колак

**8.** Сүз һәм аның русчага тәрҗемәсен тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) киң | 1) мальчик |
| Ә) мәйдан | 2) широкий |
| Б) малай | 3) площадь |

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)____________

**9.** Гарәп теленнән кергән сүзне күчереп языгыз.

*Мәктәп белем бирә.*

Җавап: ______________________

**10.** Ялгызлык исемне күчереп языгыз.

*Казанда заводлар күп.*

Җавап: _____________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**11.** 6 сүз өстәп, җөмләне тулыландырып языгыз.
Мин ... яратам.

**5 нче бүлек**

**12**. “Чын дус” темасына бәйле 5 җөмлә уйлап әйтегез.

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Биремнәрне башкару өчен, 45 минут вакыт бирелә. Тест 12 **биремне** үз эченә алган **5** бүлектән тора.

**1 нче бүлектәге** 3 бирем (1 – 3 нче биремнәр) укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләрен тикшерүгә юнәлтелгән.

**2 нче бүлектәге** 2 бирем (4 – 5 нче биремнәр) укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү максатыннан бирелә.

**3 нче бүлектәге** 3 бирем (6 – 10 нчы биремнәр) укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә кайтып кала.

**4 нче бүлектәге** 11 нче бирем укучыларның язу күнекмәләрен тикшерү өчен бирелә.

**5 нче бүлек** биреме укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен тикшерүне күздә тота.

**Уңышлар телибез!**

**1 нче бүлек**

Текстны тыңлагыз һәм 1-3 нче биремнәрне эшләгез.

**1.** Малай кайдан кайта?

1) кибеттән

2) эштән

3) мәктәптән

**2.** Малай ни өчен ашыга?

1) китап укыйсы килә

2) маҗаралы кино карыйсы килә

3) уйныйсы килә

**3.** Бу – дөресме? *Батырлар урамы шушы тирәдә.*

1) дөрес 2) дөрес түгел

**2 нче бүлек**

Җөмләләрне укыгыз. Дөрес сүзне сайлагыз. Астына сызыгыз.

**4.** Язгы аяз көннәрнең берендә (без/сез/алар) юлга чыктык.

**5**. Көн искиткеч (сылу/чибәр/матур), һава саф иде.

**3 нче бүлек**

Укыгыз һәм 6-10нчы биремнәрне эшләгез.

**6.** Хәрефләргә караганда авазлар саны күбрәк булган сүзне билгеләгез.

1) көньяк

2) яулык

3) мәгънә

**7.** Тамырдаш сүзләрне билгеләгез.

1) дару, дәрес

2) юл, юлдаш
3) бит, бил

**8.** Сүз һәм аның русчага тәрҗемәсен тәңгәлләштерегез.

| | |
|---|---|
| А) ике | 1) друг |
| Ә) ел | 2) два |
| Б) дус | 3) год |

Җавап:

1)________ 2) ________ 3)____________

**9.** Гарәп теленнән кергән сүзне күчереп языгыз.

*Марат китап укый.*

Җавап: ______________________

**10.** Ялгызлык исемне күчереп языгыз.

*Идел үтә алмаслык сазлыклардан башланып китә.*

Җавап: _____________

**4 нче бүлек**

Укыгыз һәм җавапларны языгыз.

**11.** 6 сүз өстәп, җөмләне тулыландырып языгыз.
Әнием ... ярата**.**

**5 нче бүлек**

**12**. “Дус нинди булырга тиеш?” темасына бәйле 5 җөмлә уйлап әйтегез.